УДК 930.27:94(470.41)

*А.М. Гайнетдинов*

# САМАРА ӨЛКӘСЕ КАМЫШЛЫ РАЙОНЫНЫҢ ЭПИГРАФИК МИРАСЫ

В статье представлен краткий анализ эпиграфических памятников, выявленных на кладбищах татарских населенных пунктов Камышлинского района Самарской области. В ходе экспедиции, организованной Институтом истории им. Ш. Марджани АН РТ в 2022 г., в некрополях 9 сел и деревень было обнаружено 107 эпиграфических памятников, имеющих историческое значение. Татары, проживающие в Камышлинском крае, в плане установки памятников строго соблюдали нормы шариата, стремились к экономии средств, ставили простые и небольшие памятники, не писали на них лишних слов, не изображали узоры и орнаменты. Практически все лапидарные памятники региона выполнены в упрощенном стиле, имеют небольшие размеры, их тексты врезные, очень короткие, лаконичные, а на некоторых татарских надмогильных плитах имеются только родовые тамги.

**Ключевые слова:** татарская эпиграфика, памятники, некрополи, Камышлинский район, Самарская область.

The article presents a brief analysis of epigraphic monuments found in the cemeteries of Tatar settlements in the Kamyshly district of the Samara region. 107 epigraphic monuments of historical significance were discovered in the necropolises of 9 villages during the expedition organized by the Sh. Marjani Institute of History of the Tatarstan Academy of Sciences in 2022. The Tatars living in the Kamyshly region strictly observed the norms of Sharia in terms of installing monuments, sought to save money, erected simple and small monuments, did not write unnecessary words on them, did not depict patterns and ornaments. Almost all lapidary monuments of the region are made in a simplified style, are small in size, their texts are incised, very short, laconic, and some Tatar tombstones have only family tamgas.

**Keywords:** Tatar epigraphy, monuments, necropolises, Kamyshly district, Samara region.

Соңгы елларда тарихи-мәдәни истәлекләргә игътибар артты дияргә мөмкин. Төрле оешмалар илебездә яшәүче халыкларның мәдәни мирасын саклау, файдалану, популярлаштыру өлкәсендә зур эшчәнлек алып баралар. Татар эпиграфик истәлекләрен ачыклау һәм өйрәнү эшләрендә дә бераз активлык сизелә башлады. Тик чит төбәкләрдә яшәүче милләттәшләребезнең ташъязма мирасын тикшерү өлкәсендә хәлләр мактанырлык түгел. Шуңа күрә татарлар яшәгән һәр төбәк җентекләп өйрәнелергә тиеш, әби-бабаларыбыздан сакланып калган бер генә эпиграфик ядкәрне дә игътибарсыз калдырмыйча, аларны халыкка кайтару өчен тырышырга кирәк.

Самара өлкәсе Камышлы районының борынгы кабер ташлары да фәнни-практик яктан тулысынча өйрәнелмәгән иде. 2019 елда

бу якларга оештырылган экспедиция вакытында Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты хезмәткәрләре И.Г. Гомәров һәм В.М. Усманов тарафыннан 14 гарәп язулы кабер ташы теркәлә [3: 4]. Әлеге төбәктәге татар авыллары зиратларында бүгенге көнгә кадәр сакланып калган бөтен ташъязма истәлекләрне барлау һәм өйрәнү өчен, 2022 елның маенда Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты фәнни хезмәткәре Сайрус Хәмидуллин белән фәнни экспедициягә чыктык. 1939 елга кадәр (кириллицага күчкәнче) куелган гарәп язулы кабер ташларының һәрберсен эзләп табып, фоторәсемгә төшердек, үлчәмнәрен алдык һәм текстларын укыдык. Аннан соңгылары өйрәнелмәде, чөнки таш чагыштырмача яңарак була барган саен, аның тарихи әһәмияте кими. Әлеге төбәктә XX йөзнең 50 нче елларында тулысынча гарәп графикасында язылган ташлар да бар.

Камышлы районының кайбер авылларында борынгы ташбилгеләр бөтенләй очрамады, икенчеләрендә исә аларның саны берничә дистәдән артып китте. Иң күп ташъязма истәлек сакланган сала – Яңа Ярмәк. Анда барлыгы 45 таш ачыкланды. Камышлы авылының ике зиратында 23 ташбилге табылды. Яңа Усман саласының ике зиратында исә 13 эпиграфик истәлек сакланып калганлыгы билгеле булды. Иске Ярмәк, Иске Балыклы, Чулпан авылларында да борынгы эпиграфик истәлекләрнең саны 6 га җитте. Калган торак пунктларга килгәндә, Татар Байтуганында – 5, Яңа Усманда – 3, Дәүләтколда – 2, Иске Усманда нибары 1 ташбилге табылды.

Районда табылган иң борынгы кабер ташы 1879 елга карый. Камышлы авылының борынгы зиратындагы бу эпиграфик истәлек Уразмәт Юныс улына аның улы Галиулла тарафыннан куелган. Ташта кабер иясенең шәҗәрәсе дә күрсәтелә: Уразмәт бине Юныс бине Габдулла бине Габделҗәлил бине Рәхмәтулла. Чагыштырмача борынгы саналган, 1890 елда вафат булган Бибисабира Рәхмәтулла кызына куелган кабер ташын да атап китәргә мөмкин. Яңа Усман авылының икенче зиратында да 1890 елга караган ташбилге саклана, шулай ук 1893 һәм 1898 елларга нисбәт ителгән кабер ташлары да ачыкланды. Яңа Ярмәк авылында исә 1892 елгы эпиграфик истәлек табылды. Камышлы районында тагын да борынгыраклары булган. Әмма, кызганычка каршы, алар инде юкка чыккан. Сакланганнарының язуларына зыян килсә дә, кайберләренең текстлары әле табигатьнең кырыс шартларына бирешмәгән, даталар һәм исемнәр, авырлык белән булса да укыла.

Төбәктә дин әһеленә куелган кабер ташы да табылды. Ул – Камышлы авылының икенче зиратында Шәйхеләбрар хәзрәтнеке (1931).

XIX – XX гасыр башында Камышлы төбәгендә кабер ташлары ясау өчен комташ һәм известьташ кына кулланылган. Аларны урындагы таш карьерларыннан алганнар. Ташларның барысы да примитив рәвештә уеп эшләнгән. Экспедиция вакытында рельефлы,

ягъни калкытып эшләнгән кабер ташлары очрамады. Аларны, махсус кисеп, ниндидер бер формага да салып тормаганнар, өчпочмаклы яки турыпочмаклы ташларга кабер иясе хакында кыскача гына мәгълүмат язылып, кабер өстенә урнаштырылган. Гомумән, ташка язу сәнгате Камышлы төбәгендә зур үсеш алмаган. Моңа халыкның матди хәле тәэсир иткән булса кирәк. Гадәттә, профессиональ рәвештә эшләнгән сыйфатлы ташбилгеләрне бай, югары катлау вәкилләре куйган, чөнки аларны эшләтү бик кыйммәткә төшкән. Элекке заманнарда бер таш яздыру – бер ат, югары зәвык белән ясалганы берничә ат бәясенә төшкән [4: 56]. Гади халыкның фәкать эшкәртелмәгән кыргый таш яки кечкенә агач багана һәм такта кую гына хәленнән килгән. Яңа Усман авылының икенче зиратында агачка уеп эшләнгән ике билге ачыкланды. Алар, үзенә күрә, кабер ташы функциясен үтиләр, шуңа да игътибардан читтә калырга тиеш түгелләр.

Ташка язу, бизәк төшерү процессы гаять катлаулы булып, остадан күп көч, тырышлык, сабырлык һәм сәләт соралган. Дымлы килеш җиңел эшкәртелгәнгә күрә, эш өчен җир астыннан яңа чыккан ташларны сайлаганнар [1: 52]. Кипкәч, аларга язу төшерү, әлбәттә, авыррак булган. Ташларны «еш кына ике метр озынлыгындагы зур пычкы белән дүрткел формада кисkәннәр, балта белән эшкәрткәннәр, каләм белән язганнар һәм махсус өтергеләр ярдәмендә уеп бизәк төшергәннәр. Әгәр дә эш барышында таш кибеп катыланып китсә, язарга уңайсыз була башласа, аны берникадәр вакыт су эченә салып тотканнар яисә өстенә су сибеп торганнар, һәм шул рәвешле ташны йомшартып, әүвәлге хәленә кайтарганнар» [4: 55–56].

Камышлы районында сакланган гарәп язулы кабер ташларының үлчәмнәре зур түгел. Иң зур таш 90 сантиметрдан артмый. Эпиграфик истәлекләрнең уртача озынлыгы исә нибары 45–50 сантиметр гына. Башка төбәкләр белән чагыштырганда, Камышлы районы ташлары кечкенә үлчәмнәре белән аерылып тора. Мәсәлән, Татарстанда сакланган борынгы кабер ташларының уртача озынлыгы якынча 90 сантиметр. Безнең фикеребезчә, ташларның шундый булуы Камышлы төбәге халкының тыйнаклыгы белән дә аңлатыладыр.

Гадәттә, борынгы татар ташбилгеләренә кабер иясе хакында мәгълүматтан тыш, Коръән аятьләре, хәдисләр, догалар, хикмәтле сүзләр, шигырьләр язылган. Гомумән, борынгы татар эпитафияләрен дүрт өлешкә бүләргә мөмкин: кереш, төп, дога һәм өстәмә өлешләр. Ташъязмаларның кереш өлешендә Аллаһны яисә ахирәтне искә төшерә торган сүзләр яки җөмләләр урын алган. Алар һәрвакыт Коръән иңгән телдә, ягъни гарәпчә язылып, Аллаһның исем-сыйфатлары, атрибутлары яки Коръән аятьләре һәм хәдисләрдән гыйбарәт. Шулай ук адәм баласына үлемне, ахирәтне, Аллаһны искә төшерүче сүзләр дә еш кулланылган. Халкыбызның борынгы эпитафияләренең төп өлешендә кабер иясенең, атасының исем-шәрифләре (кайвакыт бабасының да исеме яисә кыскача шәҗәрәсе, титулы), вафат булу

датасы (кайчакта үлүенең сәбәбе) һ. б. язылган. Гадәттә, бу өлеш татар телендә булган, бик сирәк очракта гына гарәп телендә яки ике телдә дә бирелгән. Эпитафияләрнең өченче өлеше – мәрхүм өчен дога кылу. Бу өлеш татар телендә дә, гарәп телендә дә булырга мөмкин. Ташка язу осталарының яратып яза торган үз догалары булган. Кабер ташының арткы һәм уң-сул якларында да өстәмә эпитафик компонентлар язылырга мөмкин. Әлеге өстәмә өлештә еш кына шигъри юллар китерелгән.

Камышлы районында сакланган күпчелек кабер ташларында исә фәкать кабер иясенең исеме, аның атасының исеме (кайбер очракта, хатын-кыз булса, иренең исеме дә) һәм үлгән елы (кайбер очракта туган елы да) күрсәтелгән. Бары тик Иске Ярмәктә Фатыйма Вәкъказ кызының кабер ташында гына «Аятел-көрси» догасы язылган, Камышлы авылының икенче зиратында Коръәндә урын алган «Иннә лилләһи вә иннә иләйһи раҗигун» («Чынлыкта, Без Аллаһныкы һәм, чынлыкта, без Аңа кайтачакбыз») сүзләре, биш ташта «Лә иләһә илләллаһ» («Аллаһтан башка гыйбадәт кылынырга лаеклы зат юк») тәүхид кәлимәсе, өч ташта бу кәлимәнең «Мөхәммәд әр-рәсүлуллаһ» («Мөхәммәд – Аллаһның илчесе») дигән дәвамы язылган. Дин галимнәре кабер ташларына артык сүзләр язуны өнәмәгән. Ризаэддин Фәхреддин ташларга ничек һәм нәрсә язылырга тиешлеген аермачык итеп язып калдырган: «Кабер ташлары нотык һәм хөтбәләр язылачак дәфтәрләр, матур язу үрнәге һәм инша язылачак кара такталар түгел. Шуның өчен вафат булучының исеме, гаилә һәм фамилиясе дөрес язылу, туу һәм вафат көннәре хатасыз теркәлү җитә» [5: 555–556].

XIX гасырда – XX гасыр башында кайвакыт саннарны кабул ителгәнчә сулдан уңга таба түгел, ә уңнан сулга таба язу очраклары күзәтелә. Гарәп телендә сүзләр һәм хәрефләр уңнан сулга таба язылганга күрә, саннар да шулай язылырга тиеш, дип уйлаганнар, күрәсең. Шулай ук киресенчә дә булган: саннарның сулдан уңга таба язылуын белгән кайбер ташка язучылар шулар янында килгән «йыл» сүзен саннарның уң ягына язганнар, мәсәлән, «1925 елда» урынына «йылда 1925» дип, «1928 елда» урынына «йылда 1928» дип, ялгыш язу күзәтелә. Камышлы төбәге кабер ташлары текстларына да менә шушы үзенчәлек хас.

Кабер өстенә язулы ташбилге кую мөмкинлеге булмаса, тамгалар уелган таш бастырылган. Камышлы районы зиратларында шундый ыру тамгалары шактый. Камышлы авылының ике зиратында барлыгы – 14, Яңа Ярмәктә – 10, Иске Ярмәктә – 5, Яңа Усманда – 3, Иске Балыклы һәм Татар Байтуганында берешәр тамга табылды.

Тамга – документларга, хезмәт коралларына, җир буйларына, терлекләргә куела яки салына торган ыру билгесе, мөһере. Нигездә, татарларда һәр нәселнең үз тамгасы булган, тик буыннар алышынган, нәсел ишәйгән саен, ул бераз үзгәрешләр дә кичергән. Кабер ташына куелган ыру билгесе аша кабер иясенең кайсы нәселгә һәм гаиләгә караганын белеп булган. Тамгаларны мөселман татарлар гына түгел,

ислам диненнән аерылып, язусыз калган керәшен татарлары да актив кулланганнар, зиратларындагы агач такталарга төрле билгеләр төшергәннәр [2: 144–145]. Тамгалар бөтен төрки халыкларда да киң таралыш алган һәм аларның, әлбәттә, рун алфавиты белән берникадәр бәйләнеше бар.

Кайбер ташбилгеләрнең өстендә, ягъни түбәсендә кечерәк кенә чокыр күрергә мөмкин. Бу, яңгыр яуганда шунда җыелган суны кошлар һәм бөҗәкләр эчә алсын өчен, шулай эшләнгән. Хайваннарга шул рәвешле яхшылык күрсәткән өчен, кабер иясенә, шулай ук ташны ясаучыга яки куючыга савап язылырга мөмкин, дип уйланылган.

Эш барышында Камышлы районының ике авылында казах милләтеннән булган өч кешенең кабер ташлары ачыкланды, шуларның икесенең тамгалары да бар. Казахларның ташбилгеләре җиңел таныла. Беренчедән, исемнәре милләтләренә ишарәләсә, икенчедән, казахлар ташларда кабер иясенең кайсы ырудан, нәселдән булуын да күрсәткәннәр. Яңа Ярмәктә 1932 елда Коранкол Татәмбәк улы һәм Душхан Имбәт улы, Чулпан авылында 1925 елда Зарман исемле кеше җирләнгән. Алар Кече җөз составына кергән Тана һәм Алаша ыруыннан булганнар. Бирегә казахлар сәүдә итү яисә дини белем алу өчен килгәннәрдер дип уйланыла. Бу факт ике милләт арасындагы тыгыз бәйләнешне күрсәтә.

Шулай итеп, Камышлы районында сакланган гарәп язулы эпиграфик истәлекләрнең барысы да диярлек өйрәнелде. Һичшиксез, алар Самара төбәге татарларының тарихын, телен һәм мәдәниятен өйрәнү чыганагы буларак зур әһәмияткә ия.

Ниһаять, Самара өлкәсе Камышлы районы зиратлары эпиграфик планда тикшерелде, дип санарга нигез бар. Без 1879–1939 елларга караган ташбилгеләрнең текстларын фәнни әйләнешкә керттек.

Камышлы төбәгендә яшәгән татарлар каберләргә ташлар кую мәсьәләсендә шәригать нормаларын төгәл үтәгәннәр, тыйнаклыкка омтылганнар, эшкәртелмәгән гади һәм зур булмаган ташбилгеләр куйганнар, аларга артык сүзләр язмаганнар, бизәкләр һәм орнаментлар төшермәгәннәр. Төбәкнең барлык лапидар һәйкәлләре гадиләштерелгән стильдә эшләнгән, зур булмаган үлчәмнәргә ия, аларның текстлары кыска, бары тик уеп язылган, кайбер татар кабер ташларында ыру тамгалары гына бар.

Камышлы районында таш кисү сәнгате зур үсеш алмаган. Моңа җирле халыкның авыр матди хәле һәм эре мөселман рухи үзәкләреннән ераклыгы тәэсир иткәндер, күрәсең. Шуңа карамастан, биредә сакланган чагыштырмача борынгы эпиграфик истәлекләр зур тарихи әһәмияткә ия һәм бердәм татар тарихи-мәдәни мирасының бер өлеше булып санала.

## Әдәбият

1. *Әхмәтҗанов М.И.* Татар археографиясенә сәхифәләр. Тарих пәрдәләре күтәрелгәндә: Фәнни-популяр хезмәт. Казан, 2012. 132 б.

2. *Макаров Г.* Ыру тамгасы, баш казыгы һәм ташбилге – борынгыдан килгән тарихи хәтер билгеләре // Проблемы изучения истории заселения и образования населенных пунктов Альметьевского региона. Казань, 2000. Б. 143–156.

3. *Усманов В.М.* Самар өлкәсе татар эпиграфик һәйкәлләре. Егерме өченче китап. Казан, 2024. 180 б.

4. *Усманов В.М.* Тарихи ядкәрләр. Уфа: ДизайнПолиграфСервис, 2005. 168 б.

5. *Фәхретдин Р.* Габдессәлам мөфтинең хәтер дәфтәре // Шура. 1913. № 18. Б. 555–556.

***Гайнетдинов Айдар Марсиль улы,***
*филология фәннәре кандидаты,*
*ТР ФА Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институтының*
*яңа тарих бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

***Гайнутдинов Айдар Марсилевич,***
*кандидат филологических наук, старший научный сотрудник*
*отдела новой истории Института истории имени Ш. Марджани АН РТ*

*aydargm@yandex.ru*